ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 6 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 8 (II өлеш), № 12 (X өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 12 (I өлеш); 2012, № 1, № 9; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның бишенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданның гаилә әгъзалары – аның белән бергә яшәүче ире йә хатыны, шулай ук бу гражданның балалары һәм ата-анасы. Гражданның башка туганнары, аның каравындагы хезмәткә сәләтсез затлар һәм аерым очракларда башка гражданнар, әгәр алар граждан тарафыннан федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә йә суд карары нигезендә аның гаилә әгъзалары буларак торакка кертелгән булса, гражданның гаилә әгъзалары булып саналырга мөмкин.»;

2) 3 статьяның 2 өлешендә «күпфункцияле үзәге» сүзләреннән соң «(алга таба – күпфункцияле үзәк)» сүзләрен өстәргә;

3) 5 статьяның бишенче абзацында «хроник авыруның» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты нигезендә билгеләнгән исемлектә каралган хроник авыруның» сүзләренә алмаштырырга, икенче җөмләне төшереп калдырырга;

4) 8 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу яисә исәпкә алудан баш тарту турында карар вәкаләтле орган тарафыннан әлеге Законның 6 статьясындагы 1 – 3 өлешләрендә күрсәтелгән гаризаны һәм документларны карау нәтиҗәләре буенча аларны тапшыру бурычы гариза бирүчегә йөкләнгән документларны тапшыру көненнән алып 30 эш көненнән дә соңга калмыйча кабул ителә. Граждан гаризаны күпфункцияле үзәк аша тапшырган очракта, исәпкә алу яисә исәпкә алудан баш тарту хакындагы карарны кабул итү срогы мондый гаризаны күпфункцияле үзәк тарафыннан вәкаләтле органга тапшыру көненнән санала.»;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Вәкаләтле орган әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән карарларның берсе кабул ителгән көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә карарларның берсен кабул итүне раслаучы документ бирә яисә аны гаризада күрсәтелгән адреска җибәрә. Гариза күпфункцияле үзәк аша тапшырылган очракта, әлеге документ, әгәр гариза бирүче аны алуның башка ысулын күрсәтмәгән булса, күпфункцияле үзәккә җибәрелә.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 9 өлеш өстәргә:

«9. Вәкаләтле орган түбәндәге очракларда гражданнарны исәпкә алудан баш тарта:

1) вәкаләтле органның соратуы буенча алынырга мөмкин булган документлардан тыш, әлеге Законның 6 статьясында каралган документлар тапшырылмаган булса;

2) тиешле документ гариза бирүче тарафыннан үз инициативасы белән тапшырылмаган очракта, дәүләт органының, җирле үзидарә органының, оешманың ведомствоара соратуга җавабында әлеге Законның 6 статьясы нигезендә гражданнарны исәпкә алу өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы күрсәтелсә, моңа мондый органнар яисә оешмалар карамагында соратып алына торган мондый документның яисә мәгълүматның булмавы тиешле гражданнарның торак урыннарына мохтаҗ буларак исәптә тору хокукын раслау очраклары керми;

3) гражданнарның торак урыннарына мохтаҗ буларак исәптә тору хокукын расламый торган документлар тапшырылган һәм (яисә) сорату буенча мондый документлар алынган булса;

4) әлеге Законның 27 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән срок тәмамланмаган булса.»;

5) 10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10 статья. **Гражданның һәм аның белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының керемен билгеләгәндә исәпкә алына торган керемнәр төрләре**

1. Исәпкә алу һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатларында гражданны һәм аның белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларын аз керемле дип тану өчен аларның керем күләмен исәпләгәндә гаиләнең һәр әгъзасының яисә ялгыз яшәүче гражданның акчалата алган керемнәре төрләре исәпкә алына, шул исәптән:

1) хезмәт бурычларын яисә башка бурычларны үтәгән өчен түләү, кызыксындыру характерындагы түләүләрне дә кертеп, башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт, граждан-хокук шартнамәсе кысаларында, шул исәптән түләү шартларында опеканы яисә попечительлекне гамәлгә ашыру турында шартнамә (тәрбиягә алган гаилә хакында шартнамә, патронат гаилә турында шартнамә) буенча, кылынган гамәл өчен түләү, директорларга түләү һәм оешманың – Россия Федерациясе салым резидентының идарә органы (директорлар советы яисә башка шундый орган) әгъзалары ала торган бүтән шундый түләүләр, мондый оешманың булу (идарә итү) урыны бу затларга йөкләнгән идарә итү бурычлары фактта үтәлгән яисә мондый түләү башкарылган урынга бәйсез рәвештә Россия Федерациясе була, моңа түбәндәгеләр керми:

а) «Гаиләне һәм ялгыз яшәүче гражданны аз керемле дип тану һәм аларга дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү өчен гаиләнең керемнәрен исәпкә алу, гаиләнең җан башына керемен исәпләү һәм ялгыз яшәүче гражданның керемен исәпкә алу тәртибе турында» Федераль законның 4 статьясында каралган хисап чорында 18 яше тулмаган һәм әлеге чорда гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында һәм (яисә) югары белем бирү мәгариф оешмасында көндезге уку рәвешендә, бары тик өстәмә белем бирү программалары буенча гына укудан тыш, кимендә алты ай белем алган балалар алган түләүләр;

б) Россия Федерациясе законнары нигезендә эш бирүче аша түләнгән салымны кайтару хокукын алуга бәйле рәвештә физик затлар керемнәренә кайтарылган салым суммалары, шулай ук салым чоры тәмамланганнан соң түләнгән салымнарны кайтаруны исәпкә алып салым базасын яңадан исәпләгәннән соң кайтарылган акчалар;

2) пенсияләр, пособиеләр һәм башка шундый түләүләр, шул исәптән мәҗбүри социаль иминият түләүләре һәм Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнары, җирле үзидарә органнары актлары (карарлары) нигезендә алынган компенсация характерындагы түләүләр, моңа түбәндәгеләр керми:

а) дәүләт социаль ярдәме турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә акчалата түләүләр рәвешендә күрсәтелә торган дәүләт социаль ярдәме, пенсиягә өстәмә социаль түләүләрдән тыш;

б) кешенең тормышына һәм сәламәтлегенә, аның шәхси мөлкәтенә һәм аның гаилә әгъзаларының гомуми милкендәге мөлкәткә килгән зыянны каплау өчен

түләнә торган бер мәртәбә иминият түләүләре, шулай ук дәүләт медик-социаль экспертиза хезмәте учреждениесе карары нигезендә медицина реабилитациясенә, социаль һәм һөнәри реабилитациягә өстәмә чыгымнарга бәйле айлык суммалар;

в) табигый бәла-казаларга яисә башка гадәттән тыш хәлләргә, шулай ук террорчылык актына бәйле рәвештә федераль бюджет, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары, җирле бюджетлар һәм башка чыганаклар акчалары исәбеннән түләнә торган бер мәртәбә матди ярдәм;

г) баланы дәвалау өчен федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджетлар һәм башка чыганаклар акчалары исәбеннән түләнә торган бер мәртәбә матди ярдәм;

д) «Балалы гаиләләргә өстәмә дәүләт ярдәме чаралары турында» Федераль законда каралган ана (гаилә) капиталының инвалид балаларны җәмгыятькә социаль яраклаштыру һәм интеграцияләү өчен билгеләнгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуга, йә индивидуаль торак төзелеше объектын төзүгә (реконструкцияләүгә), аны төзү (реконструкцияләү) чыгымнарын компенсацияләүгә, йә блоклы төзелә торган йортны реконструкцияләүгә, аны реконструкцияләү чыгымнарын компенсацияләүгә юнәлдерелгән акчалары, шулай ук ана (гаилә) региональ капиталы акчалары;

е) «Герой ана» исеме биргәндә, «Ата-ана даны» ордены, «Ата-ана даны» ордены медале белән бүләкләгәндә түләнә торган «Россия Федерациясе дәүләт бүләкләү системасын камилләштерүнең кайбер мәсьәләләре турында» 2022 елның 15 августындагы 558 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указының 3 һәм 4 пунктларында һәм «Ата-ана даны» орденын гамәлгә кую турында» 2008 елның 13 маендагы 775 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указының 4 пунктында билгеләнгән бер мәртәбә акчалата түләүләр;

ж) «Ата-ана фидакарьлеге» медале, «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләгәндә түләнә торган «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 37 статьясындагы 2 өлеше нигезендә билгеләнгән бер мәртәбә акчалата түләүләр;

з) 18 яшькә кадәрге инвалид баланы яисә балачактан I төркем инвалидны карап торучы эшләмәүче хезмәткә сәләтле затларга айлык акчалата түләүләр (шул исәптән «Инвалид балаларны һәм балачактан I төркем инвалидларны карап торучы затларга айлык түләүләр турында» 2013 елның 26 февралендәге 175 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указының 1 пунктындагы «б» пунктчасында билгеләнгән түләүләр);

и) инвалидны реабилитацияләүнең яисә абилитацияләүнең индивидуаль программасы нигезендә инвалид үзе сатып алган техник реабилитацияләү чарасы өчен һәм (яисә) күрсәтелгән хезмәт өчен компенсацияләр, шулай ук сукырларны йөртә торган этләрне тоту һәм аларга ветеринария хезмәте күрсәтү чыгымнарына «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль закон нигезендә бирелә торган еллык акчалата компенсацияләр;

к) мәет җирләүгә «Мәет җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законда билгеләнгән социаль пособие;

л) кабер ташларын әзерләүгә һәм урнаштыруга компенсацияләр;

м) сатып алу бәясе максатчан дәүләт социаль ярдәме кысаларында тулы күләмдә түләнгән күчемсез мөлкәт, автотранспорт яисә мототранспорт чарасы, үзйөрешле машина сатып алуга акчалар;

3) һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында белем алучы затларга, фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча көндезге уку рәвешендә белем алучы затларга, дини белем бирү оешмаларында белем алучы затларга түләнә торган Россия Федерациясе законнарында каралган стипендияләр һәм башка акчалата түләүләр, шулай ук әлеге категорияләрдәге гражданнарга медицина күрсәтмәләре буенча академик ялда булу чорында компенсация түләүләре;

4) алынган алиментлар суммасы;

5) Россия Федерациясенең мәҗбүри пенсия иминияте турындагы законнарында каралган очракларда вафат булган иминләштерелгән затларның хокук дәвамчыларына түләүләр;

6) хәрби хезмәткәрләрнең, ирекле формированиеләрдә булган гражданнарның, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, Россия Федерациясе җинаять-башкару системасы учреждениеләре һәм органнары, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнары, Россия Федерациясе таможня органнары һәм Россия Федерациясе законнарында хокук саклау эшчәнлегенә бәйле булган федераль дәүләт хезмәтен узу каралган башка органнар хезмәткәрләренең акчалата тәэминаты (аларга акчалата түләү), шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән даими бирелә торган өстәмә түләүләр һәм азык-төлек белән тәэмин итү (азык-төлек паегы урынына акчалата компенсация) (булганда), хәрби хезмәткәрләргә, ирекле формированиеләрдә булган гражданнарга яисә аларның гаилә әгъзаларына хәрби хәрәкәтләрдә катнашуга бәйле рәвештә аларның тормышына һәм сәламәтлегенә килгән зыянны каплау өчен түләнә торган Россия Федерациясе законнарында һәм Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында каралган бер мәртәбә түләүләрдән тыш;

7) дәүләт бурычларын яисә иҗтимагый бурычларны үтәү чоры өчен дәүләт органы яисә иҗтимагый берләшмә тарафыннан түләнә торган компенсацияләр, «Гаиләне һәм ялгыз яшәүче гражданны аз керемле дип тану һәм аларга дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү өчен гаиләнең керемнәрен исәпкә алу, гаиләнең җан башына керемен исәпләү һәм ялгыз яшәүче гражданның керемен исәпкә алу тәртибе турында» Федераль законның 4 статьясында каралган хисап чорында 18 яше тулмаган һәм әлеге чорда гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында һәм (яисә) югары белем бирү мәгариф оешмасында көндезге уку рәвешендә (бары тик өстәмә белем бирү программалары буенча гына укудан тыш) дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә дә, күрсәтү турында гариза бирү аена кадәрге ай алдындагы 12 айга туры килгән чорда кимендә алты ай белем алган балалар алган компенсацияләрдән тыш;

8) гражданнарга социаль ярдәм чаралары буларак бирелә торган һәм торак урыны, коммуналь хезмәт күрсәтүләр яисә транспорт хезмәт күрсәтүләре өчен түләүгә бәйле булган акчалата түләүләр (компенсацияләр);

9) кыйммәтле кәгазьләр белән операцияләр һәм икенчел финанс инструментлары белән операцияләр буенча, шулай ук оешма милкенә идарә итүдә катнашуга бәйле рәвештә алынган дивидендлар, процентлар һәм башка керемнәр;

10) банклардагы кертемнәр (счетларда калган акчалар) буенча процентлар рәвешендәге керемнәр, опекада (попечительлектә) булган 18 яшькә кадәрге балаларга ачылган банклардагы номиналь счетлар буенча процентлар рәвешендәге керемнәрдән тыш;

11) эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырудан керемнәр, крестьян (фермер) хуҗалыгының, шул исәптән юридик зат төземичә генә булдырылган мондый хуҗалыкның, эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәрне дә кертеп, һәм хосусый практика белән шөгыльләнүдән керемнәр (гариза бирүче яисә аның гаилә әгъзалары максатчан тоту характерына ия булган һәм эшкуарлыкка ярдәм итү кысаларында бирелә торган грантлар, субсидияләр һәм башка кертемнәр турында документлар (белешмәләр) тапшырырга хокуклы булган мондый грантлардан, субсидияләрдән һәм башка кертемнәрдән тыш);

12) мөлкәтне реализацияләүдән һәм аны арендага (наемга, поднаемга) бирүдән керемнәр;

13) авторлык заказы шартнамәләре, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә махсус хокукны читләштерү турында шартнамәләр һәм лицензия шартнамәләре буенча керемнәр;

14) «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллану кысаларында алынган керемнәр;

15) отставкага чыккан судьяларга гомерлек айлык түләү;

16) хәрби хезмәттән, Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрендә, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнарында, Россия Федерациясе таможня органнарында, Россия Федерациясе Президентының Баш махсус программалар идарәсендә, Россия Федерациясе җинаять-башкару системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, федераль иминлек хезмәте органнарында, Россия Федерациясе дәүләт саклавы органнарында, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарында, Россия Федерациясе законнарында хокук саклау эшчәнлегенә бәйле булган федераль дәүләт хезмәтен узу каралган башка органнарда хезмәт итүдән азат ителгәндә бер мәртәбә түләнә торган пособие;

17) гариза бирүче яисә аның гаилә әгъзалары тарафыннан Россия Федерациясеннән читтә алынган керем;

18) лотереяларны, тотализаторларны һәм башка хәтәр уеннарны оештыручылар тарафыннан түләнә торган җиңүләр нәтиҗәсендә алынган керемнәр;

19) гариза бирүченең яисә аның гаилә әгъзаларының мәгариф оешмаларында белем алуларына түләү өчен теләсә кайсы чыганаклардан җибәрелгән акчалар (гариза бирүченең яисә аның гаилә әгъзаларының үз акчаларыннан тыш);

20) «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы, «Ветераннар турында» Федераль закон, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль закон, «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга социаль

гарантияләр турында» Федераль закон һәм «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе кайбер закон актларының үз көчен югалтуын тану хакында» Федераль закон нигезендә билгеләнгән төрле категориядәге гражданнарга айлык акчалата түләүләр һәм компенсацияләр суммасы.

2. Гаиләнең яисә ялгыз яшәүче гражданның керемендә әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 пунктының «а» һәм «б» пунктчаларында, 2 пунктының «а» – «м» пунктчаларында күрсәтелгән керемнәрдән башка түбәндәге керемнәр төрләре дә исәпкә алынмый:

1) эш эзләүче гражданнар, эшсез гражданнар «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Федераль закон нигезендә эш белән тәэмин итү хезмәте органнары җибәрүе буенча башка урында эшкә урнашу өчен күчеп киткәндә бирелә торган финанс ярдәме;

2) түләнгән алиментлар суммасы;

3) «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы, «Ветераннар турында» Федераль закон, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль закон, «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга социаль гарантияләр турында» Федераль закон һәм «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе кайбер закон актларының үз көчен югалтуын тану хакында» Федераль закон нигезендә төрле категориядәге гражданнарга бирелә торган еллык компенсацияләр һәм бер мәртәбә түләнә торган пособиеләр;

4) түбәндәге затлар тарафыннан аларның булу урыны буенча алына торган керемнәр:

а) сержантлар, старшиналар, солдатлар яисә матрослар буларак чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләр, шулай ук хәрби һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү хәрби мәгариф оешмаларында белем алучы һәм хәрби хезмәт үтү турында контракт төземәгән хәрби хезмәткәрләр;

б) иректән мәхрүм ителү рәвешендә җәза үтүче затлар, сак астында тоту рәвешендәге җәза чарасы кулланылган затлар, шулай ук суд карары буенча мәҗбүри дәваланудa булган затлар;

в) интернаты булган оешмаларда тулысынча дәүләт тәэминатында яшәүче затлар;

г) хәбәрсез югалган һәм эзләүдәге затлар.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендәге 4 пунктында күрсәтелгән затлар өчен банкларда һәм башка кредит оешмаларында кертемнәр буенча керемнәр, күчемле һәм (яисә) күчемсез мөлкәтне наемга, поднаемга яисә арендага бирүдән керемнәр һәм аларны алу бу затларның булу урынына бәйле булмаган бүтән шундый ук керемнәр исәпкә алына.»;

6) 11 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

7) 12 статьяда:

а) 3 өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Индивидуаль эшкуарларның керемнәре вәкаләтле органга кәгазь чыганакта күрсәтелергә тиешле салым салуның гомуми системасын да, гадиләштерелгән системасын да кулланучы индивидуаль эшкуарның керемнәрен һәм чыгымнарын, хуҗалык операцияләрен исәпкә алу кенәгәсендәге, салым салуның патент системасын кулланучы индивидуаль эшкуарның керемнәрен исәпкә алу кенәгәсендәге, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр өчен салым салу системасын (бердәй авыл хуҗалыгы салымын) кулланучы индивидуаль эшкуарның керемнәрен һәм чыгымнарын исәпкә алу кенәгәсендәге белешмәләр белән расланырга тиеш.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:

«$3^1$. «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимына күчкән физик затларның, шул исәптән индивидуаль эшкуарларның, керемнәре вәкаләтле органга кәгазь чыганакта күрсәтелергә тиешле һөнәри керемгә салым буенча исәп-хисапның торышы (керемнәр) турында белешмә белән раслана.»;

8) 13 статьяда:

а) 1 өлештә «керемнәре тиешле социаль-демографик төркемнең яшәү минимумына тигез дип санала» сүзләрен «кереме Татарстан Республикасында тиешле социаль-демографик төркем өчен билгеләнгән яшәү минимумына тигез дип санала» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «, әлеге статьяның 3 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен төшереп калдырырга, «тиешле социаль-демографик төркем өчен» сүзләрен «Татарстан Республикасында тиешле социаль-демографик төркем өчен билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

9) 21 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Исәпкә алынган гражданнарның керемнәрен һәм мөлкәтенең хакын аз керемле буларак аларның статусын һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары алу хокукын даими рәвештә яңадан раслау максатларында яңадан бәяләүне (алга таба – яңадан бәяләү) үткәрүнең кабатланып торуы һәм аның сроклары җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«1[1]. Яңадан бәяләү торак урыннарына мохтаҗ буларак исәптә торучы гражданнарны әлеге Законның 24 статьясында каралган яңадан теркәү процедурасы белән бер үк вакытта башкарыла.»;

в) 2 өлештә «агымдагы елның 1 апреленә кадәр» сүзләрен төшереп калдырырга;

10) 22 статьяның 3 өлешендәге бишенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

11) 23 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

12) 24 статьяда:

а) 2 өлештә «ел саен 1 гыйнвардан алып 1 майга кадәрге чорда» сүзләрен «әлеге Законның 21 статьясында каралган яңадан бәяләү белән бер үк вакытта» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Торак урыннарына мохтаҗ буларак исәптә торучы гражданнарны яңадан теркәү өчен әлеге Законның 21 статьясындагы 2 өлеше нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан яңадан бәяләү өчен алына торган документлардан башка түбәндәге документлар кирәк:»;

в) түбәндәге эчтәлекле 3[1] өлеш өстәргә:

«3[1]. 2005 елның 1 мартына кадәр исәпкә алынган гражданнар яңадан теркәүне үтү өчен вәкаләтле органга аларны тапшыру бурычы гражданга йөкләнгән, гражданнарга Россия Федерациясе Торак кодексы гамәлгә кергәнче торак урыннары алу хокукы биргән нигезләрне раслаучы документларны (аларның күчермәләрен яисә аларда булган белешмәләрне) тапшырырга (җибәрергә) тиеш.»;

г) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Әгәр торак урыннарына мохтаҗ буларак исәптә торучы гражданнарны яңадан теркәүне үткәрү барышында гражданның торак урынына мохтаҗ булу статусын раслау нигезләренә ия булмавы билгеләнсә, вәкаләтле орган әлеге Законның 25 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән тәртиптә гражданны торак урынына мохтаҗ буларак исәптән төшерү турында карар кабул итә.»;

13) 25 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле 1[1] өлеш өстәргә:

«1[1]. 2005 елның 1 мартына кадәр алга таба социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатларында исәпкә алынган гражданнар мондый исәптән әлеге статьяның 1 өлешендәге икенче, дүртенче – җиденче абзацларында каралган нигезләр буенча, шулай ук бу гражданнар Россия Федерациясе Торак кодексы гамәлгә кергәнче социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары алу хокукы биргән нигезләрне югалткан очракта төшереләләр.»;

б) 2 өлештә татарча текст үзгәрешсез кала.

**2 статья**

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 статья. **Гражданның һәм аның белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының керемен билгеләгәндә исәпкә алына торган керемнәр төрләре**

1. Гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннары алуга мохтаҗ дип тану максатларында гражданның һәм аның белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының керем күләмен исәпләгәндә гаиләнең һәр әгъзасының яисә ялгыз яшәүче гражданның акчалата алган керемнәре төрләре исәпкә алына, шул исәптән:

1) хезмәт бурычларын яисә башка бурычларны үтәгән өчен түләү, кызыксындыру характерындагы түләүләрне дә кертеп, башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт, граждан-хокук шартнамәсе кысаларында, шул исәптән түләү шартларында опеканы яисә попечительлекне гамәлгә ашыру турында шартнамә (тәрбиягә алган гаилә хакында шартнамә, патронат гаилә турында шартнамә) буенча, кылынган гамәл өчен түләү, директорларга түләү һәм оешманың – Россия Федерациясе салым резидентының идарә органы (директорлар советы яисә башка шундый орган) әгъзалары ала торган бүтән шундый түләүләр, мондый оешманың булу (идарә итү) урыны бу затларга йөкләнгән идарә итү бурычлары фактта үтәлгән яисә мондый түләү башкарылган урынга бәйсез рәвештә Россия Федерациясе була, моңа түбәндәгеләр керми:

а) «Гаиләне һәм ялгыз яшәүче гражданны аз керемле дип тану һәм аларга дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү өчен гаиләнең керемнәрен исәпкә алу, гаиләнең җан башына керемен исәпләү һәм ялгыз яшәүче гражданның керемен исәпкә алу тәртибе турында» Федераль законның 4 статьясында каралган хисап чорында 18 яше тулмаган һәм әлеге чорда гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында һәм (яисә) югары белем бирү мәгариф оешмасында көндезге уку рәвешендә, бары тик өстәмә белем бирү программалары буенча гына укудан тыш, кимендә алты ай белем алган балалар алган түләүләр;

б) Россия Федерациясе законнары нигезендә эш бирүче аша түләнгән салымны кайтару хокукын алуга бәйле рәвештә физик затлар керемнәренә кайтарылган салым суммалары, шулай ук салым чоры тәмамланганнан соң түләнгән салымнарны кайтаруны исәпкә алып салым базасын яңадан исәпләгәннән соң кайтарылган акчалар;

2) пенсияләр, пособиеләр һәм башка шундый түләүләр, шул исәптән мәҗбүри социаль иминият түләүләре һәм Россия Федерациясе законнары һәм (яисә)

Татарстан Республикасы законнары, җирле үзидарә органнары актлары (карарлары) нигезендә алынган компенсация характерындагы түләүләр, моңа түбәндәгеләр керми:

а) дәүләт социаль ярдәме турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә акчалата түләүләр рәвешендә күрсәтелә торган дәүләт социаль ярдәме, пенсиягә өстәмә социаль түләүләрдән тыш;

б) кешенең тормышына һәм сәламәтлегенә, аның шәхси мөлкәтенә һәм аның гаилә әгъзаларының гомуми милкендәге мөлкәткә килгән зыянны каплау өчен түләнә торган бер мәртәбә иминият түләүләре, шулай ук дәүләт медик-социаль экспертиза хезмәте учреждениесе карары нигезендә медицина реабилитациясенә, социаль һәм һөнәри реабилитациягә өстәмә чыгымнарга бәйле айлык суммалар;

в) табигый бәла-казаларга яисә башка гадәттән тыш хәлләргә, шулай ук террорчылык актына бәйле рәвештә федераль бюджет, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары, җирле бюджетлар һәм башка чыганаклар акчалары исәбеннән түләнә торган бер мәртәбә матди ярдәм;

г) баланы дәвалау өчен федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджетлар һәм башка чыганаклар акчалары исәбеннән түләнә торган бер мәртәбә матди ярдәм;

д) «Балалы гаиләләргә өстәмә дәүләт ярдәме чаралары турында» Федераль законда каралган ана (гаилә) капиталының инвалид балаларны җәмгыятькә социаль яраклаштыру һәм интеграцияләү өчен билгеләнгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуга, йә индивидуаль торак төзелеше объектын төзүгә (реконструкцияләүгә), аны төзү (реконструкцияләү) чыгымнарын компенсацияләүгә, йә блоклы төзелә торган йортны реконструкцияләүгә, аны реконструкцияләү чыгымнарын компенсацияләүгә юнәлдерелгән акчалары, шулай ук ана (гаилә) региональ капиталы акчалары;

е) «Герой ана» исеме биргәндә, «Ата-ана даны» ордены, «Ата-ана даны» ордены медале белән бүләкләгәндә түләнә торган «Россия Федерациясе дәүләт бүләкләү системасын камилләштерүнең кайбер мәсьәләләре турында» 2022 елның 15 августындагы 558 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указының 3 һәм 4 пунктларында һәм «Ата-ана даны» орденын гамәлгә кую турында» 2008 елның 13 маендагы 775 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указының 4 пунктында билгеләнгән бер мәртәбә акчалата түләүләр;

ж) «Ата-ана фидакарьлеге» медале, «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләгәндә түләнә торган «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 37 статьясындагы 2 өлеше нигезендә билгеләнгән бер мәртәбә акчалата түләүләр;

з) 18 яшькә кадәрге инвалид баланы яисә балачактан I төркем инвалидны карап торучы эшләмәүче хезмәткә сәләтле затларга айлык акчалата түләүләр (шул исәптән «Инвалид балаларны һәм балачактан I төркем инвалидларны карап торучы затларга айлык түләүләр турында» 2013 елның 26 февралендәге 175 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указының 1 пунктындагы «б» пунктчасында билгеләнгән түләүләр);

и) инвалидны реабилитацияләүнең яисә абилитацияләүнең индивидуаль программасы нигезендә инвалид үзе сатып алган техник реабилитацияләү чарасы өчен һәм (яисә) күрсәтелгән хезмәт өчен компенсацияләр, шулай ук сукырларны йөртә торган этләрне тоту һәм аларга ветеринария хезмәте күрсәтү чыгымнарына «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль закон нигезендә бирелә торган еллык акчалата компенсацияләр;

к) мәет җирләүгә «Мәет җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законда билгеләнгән социаль пособие;

л) кабер ташларын әзерләүгә һәм урнаштыруга компенсацияләр;

м) сатып алу бәясе максатчан дәүләт социаль ярдәме кысаларында тулы күләмдә түләнгән күчемсез мөлкәт, автотранспорт яисә мототранспорт чарасы, үзйөрешле машина сатып алуга акчалар;

3) һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында белем алучы затларга, фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча көндезге уку рәвешендә белем алучы затларга, дини белем бирү оешмаларында белем алучы затларга түләнә торган Россия Федерациясе законнарында каралган стипендияләр һәм башка акчалата түләүләр, шулай ук әлеге категорияләрдәге гражданнарга медицина күрсәтмәләре буенча академик ялда булу чорында компенсация түләүләре;

4) алынган алиментлар суммасы;

5) Россия Федерациясенең мәҗбүри пенсия иминияте турындагы законнарында каралган очракларда вафат булган иминләштерелгән затларның хокук дәвамчыларына түләүләр;

6) хәрби хезмәткәрләрнең, ирекле формированиеләрдә булган гражданнарның, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, Россия Федерациясе җинаять-башкару системасы учреждениеләре һәм органнары, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнары, Россия Федерациясе таможня органнары һәм Россия Федерациясе законнарында хокук саклау эшчәнлегенә бәйле булган федераль дәүләт хезмәтен узу каралган башка органнар хезмәткәрләренең акчалата тәэминаты (аларга акчалата түләү), шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән даими бирелә торган өстәмә түләүләр һәм азык-төлек белән тәэмин итү (азык-төлек паегы урынына акчалата компенсация) (булганда), хәрби хезмәткәрләргә, ирекле формированиеләрдә булган гражданнарга яисә аларның гаилә әгъзаларына хәрби хәрәкәтләрдә катнашуга бәйле рәвештә аларның тормышына һәм сәламәтлегенә килгән зыянны каплау өчен түләнә торган Россия Федерациясе законнарында һәм Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында каралган бер мәртәбә түләүләрдән тыш;

7) дәүләт бурычларын яисә иҗтимагый бурычларны үтәү чоры өчен дәүләт органы яисә иҗтимагый берләшмә тарафыннан түләнә торган компенсацияләр, «Гаиләне һәм ялгыз яшәүче гражданны аз керемле дип тану һәм аларга дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү өчен гаиләнең керемнәрен исәпкә алу, гаиләнең җан башына керемен исәпләү һәм ялгыз яшәүче гражданның керемен исәпкә алу тәртибе турында» Федераль законның 4 статьясында каралган хисап чорында 18 яше тулмаган һәм әлеге чорда гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем

бирү оешмасында һәм (яисә) югары белем бирү мәгариф оешмасында көндезге уку рәвешендә (бары тик өстәмә белем бирү программалары буенча гына укудан тыш) дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә дә, күрсәтү турында гариза бирү аена кадәрге ай алдындагы 12 айга туры килгән чорда кимендә алты ай белем алган балалар алган компенсацияләрдән тыш;

8) гражданнарга социаль ярдәм чаралары буларак бирелә торган һәм торак урыны, коммуналь хезмәт күрсәтүләр яисә транспорт хезмәт күрсәтүләре өчен түләүгә бәйле булган акчалата түләүләр (компенсацияләр);

9) кыйммәтле кәгазьләр белән операцияләр һәм икенчел финанс инструментлары белән операцияләр буенча, шулай ук оешма милкенә идарә итүдә катнашуга бәйле рәвештә алынган дивидендлар, процентлар һәм башка керемнәр;

10) банклардагы кертемнәр (счетларда калган акчалар) буенча процентлар рәвешендәге керемнәр, опекада (попечительлектә) булган 18 яшькә кадәрге балаларга ачылган банклардагы номиналь счетлар буенча процентлар рәвешендәге керемнәрдән тыш;

11) эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырудан керемнәр, крестьян (фермер) хуҗалыгының, шул исәптән юридик зат төземичә генә булдырылган мондый хуҗалыкның, эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәрне дә кертеп, һәм хосусый практика белән шөгыльләнүдән керемнәр (гариза бирүче яисә аның гаилә әгъзалары максатчан тоту характерына ия булган һәм эшкуарлыкка ярдәм итү кысаларында бирелә торган грантлар, субсидияләр һәм башка кертемнәр турында документлар (белешмәләр) тапшырырга хокуклы булган мондый грантлардан, субсидияләрдән һәм башка кертемнәрдән тыш);

12) мөлкәтне реализацияләүдән һәм аны арендага (наемга, поднаемга) бирүдән керемнәр;

13) авторлык заказы шартнамәләре, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә махсус хокукны читләштерү турында шартнамәләр һәм лицензия шартнамәләре буенча керемнәр;

14) «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллану кысаларында алынган керемнәр;

15) отставкага чыккан судьяларга гомерлек айлык түләү;

16) хәрби хезмәттән, Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрендә, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнарында, Россия Федерациясе таможня органнарында, Россия Федерациясе Президентының Баш махсус программалар идарәсендә, Россия Федерациясе җинаять-башкару системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, федераль иминлек хезмәте органнарында, Россия Федерациясе дәүләт саклавы органнарында, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарында, Россия Федерациясе законнарында хокук саклау эшчәнлегенә бәйле булган федераль дәүләт хезмәтен узу каралган башка органнарда хезмәт итүдән азат ителгәндә бер мәртәбә түләнә торган пособие;

17) гариза бирүче яисә аның гаилә әгъзалары тарафыннан Россия Федерациясеннән читтә алынган керем;

18) лотереяларны, тотализаторларны һәм башка хәтәр уеннарны оештыручылар тарафыннан түләнә торган җиңүләр нәтиҗәсендә алынган керемнәр;

19) гариза бирүченең яисә аның гаилә әгъзаларының мәгариф оешмаларында белем алуларына түләү өчен теләсә кайсы чыганаклардан җибәрелгән акчалар (гариза бирүченең яисә аның гаилә әгъзаларының үз акчаларыннан тыш);

20) «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы, «Ветераннар турында» Федераль закон, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль закон, «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга социаль гарантияләр турында» Федераль закон һәм «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе кайбер закон актларының үз көчен югалтуын тану хакында» Федераль закон нигезендә билгеләнгән төрле категориядәге гражданнарга айлык акчалата түләүләр һәм компенсацияләр суммасы.

2. Гаиләнең яисә ялгыз яшәүче гражданның керемендә әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 пунктының «а» һәм «б» пунктчаларында, 2 пунктының «а» – «м» пунктчаларында күрсәтелгән керемнәрдән башка түбәндәге керемнәр төрләре дә исәпкә алынмый:

1) эш эзләүче гражданнар, эшсез гражданнар «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Федераль закон нигезендә эш белән тәэмин итү хезмәте органнары җибәрүе буенча башка урында эшкә урнашу өчен күчеп киткәндә бирелә торган финанс ярдәме;

2) түләнгән алиментлар суммасы;

3) «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы, «Ветераннар турында» Федераль закон, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль закон, «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга социаль гарантияләр турында» Федераль закон һәм «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе кайбер закон актларының үз көчен югалтуын тану хакында» Федераль закон нигезендә төрле категориядәге гражданнарга бирелә торган еллык компенсацияләр һәм бер мәртәбә түләнә торган пособиеләр;

4) түбәндәге затлар тарафыннан аларның булу урыны буенча алына торган керемнәр:

а) сержантлар, старшиналар, солдатлар яисә матрослар буларак чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләр, шулай ук хәрби һөнәри белем бирү

оешмаларында һәм югары белем бирү хәрби мәгариф оешмаларында белем алучы һәм хәрби хезмәт үтү турында контракт төземәгән хәрби хезмәткәрләр;

б) иректән мәхрүм ителү рәвешендә җәза үтүче затлар, сак астында тоту рәвешендәге җәза чарасы кулланылган затлар, шулай ук суд карары буенча мәҗбүри дәвалануда булган затлар;

в) интернаты булган оешмаларда тулысынча дәүләт тәэминатында яшәүче затлар;

г) хәбәрсез югалган һәм эзләүдәге затлар.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендәге 4 пунктында күрсәтелгән затлар өчен банкларда һәм башка кредит оешмаларында кертемнәр буенча керемнәр, күчемле һәм (яисә) күчемсез мөлкәтне наемга, поднаемга яисә арендага бирүдән керемнәр һәм аларны алу бу затларның булу урынына бәйле булмаган бүтән шундый ук керемнәр исәпкә алына.»;

2) 7 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 8 статьяда:

а) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Индивидуаль эшкуарларның керемнәре вәкаләтле органга кәгазь чыганакта күрсәтелергә тиешле салым салуның гомуми системасын да, гадиләштерелгән системасын да кулланучы индивидуаль эшкуарның керемнәрен һәм чыгымнарын, хуҗалык операцияләрен исәпкә алу кенәгәсендәге, салым салуның патент системасын кулланучы индивидуаль эшкуарның керемнәрен исәпкә алу кенәгәсендәге, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр өчен салым салу системасын (бердәй авыл хуҗалыгы салымын) кулланучы индивидуаль эшкуарның керемнәрен һәм чыгымнарын исәпкә алу кенәгәсендәге белешмәләр белән расланырга тиеш.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $5^1$ өлеш өстәргә:

«$5^1$. «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимына күчкән физик затларның, шул исәптән индивидуаль эшкуарларның, керемнәре вәкаләтле органга кәгазь чыганакта күрсәтелергә тиешле һөнәри керемгә салым буенча исәп-хисапның торышы (керемнәр) турында белешмә белән раслана.»;

4) 9 статьяда:

а) 1 өлештә «керемнәре аларның күрсәтелгән оешмаларда яшәгән айлары өчен тиешле социаль-демографик төркемгә туры килә торган» сүзләрен «кереме аларның күрсәтелгән оешмаларда яшәгән айлары өчен Татарстан Республикасында тиешле социаль-демографик төркем өчен билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «, әлеге статьяның 3 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен төшереп калдырырга, «тиешле социаль-демографик төркем өчен» сүзләрен «Татарстан Республикасында тиешле социаль-демографик төркем өчен билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 18 июнь
№ 47-ТРЗ